| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| --- | --- |
| **Исполнительный комитет поселка городского типа Уруссу Ютазинского муниципального района** | **Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты** |
| 423950, п.г.т. Уруссу<br>ул. Пушкина, 38<br>тел. 2-61-50<br>2-92-40 | 423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы<br>Пушкин урамы, 38<br>тел. 2-61-50<br>2-92-40 |


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 11 01.03.2016 ел

**Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару сорауларын җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның $43^1$ статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы тарафыннан 2016 елның 1 мартыннан төзелгән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен үзара хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгының 2016 елның 12 февралендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җыю һәм җибәрү буенча үзара эшчәнлек регламентына һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җыю буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгының 2016 елның 12

феврalendəге 13 номерлы карарына таянырга.

2. Урыссу шәһәр тибындагы поселок Советының, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы башлыгының һәм Урыссу шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актларын район башкарма комитетына , шулай ук регистрга кертелергә тиешле алар турында белешмәләрне җибәрү өчен җаваплы итеп Урыссу шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетының әйдәүче белгечен билгеләргә.

3. Әлеге карарны Урыссу ш.т.п., Пушкин ур., 38 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендында игълан итәргә: һәм www.yutaza.tatar.ru адресы буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Ф. Вәдигуллин